ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422701, Высокогорский район РТ,
с. Высокая Гора, ул. Б. Красная, д.113 А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕКТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422701, ТР Биектау районы,
Биектау авылы, Зур Кызыл ур.113 А

Тел./факс: +7(84365) 74-778, e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**30 апрель 2025 ел** **№ 8**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 нчы елның 2 нче декабрендәге 102 нче номерлы «Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитетының Бердәм тариф челтәренә кагылмый торган баш бухгалтер һәм бухгалтерларның, бюджет өлкәсендә аерым оешмалар хезмәткәрләренең, Биектау авыл җирлеге башкарма комитетының хәрби-хисап хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Шәһәр һәм авыл җирлекләре үзәкләштерелгән бухгалтерияләре һәм бухгалтерлары җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте турында» 2025 елның 03 апрелендәге 03-12/2212 номерлы хаты нигезендә һәм муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү системасын камилләштерү максатларында Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 нче елның 1 нче маеннан Башкарма комитетның 2019 нчы елның 2 нче декабрендәге 102 нче номерлы «Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитетының Бердәм тариф челтәренә кагылмый торган баш бухгалтер һәм бухгалтерларның, бюджет өлкәсендә аерым оешмалар хезмәткәрләренең, Биектау авыл җирлеге башкарма комитетының хәрби-хисап хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» карары белән расланган баш бухгалтерларның һәм үзәкләштерелгән бухгалтерларның айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. «Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегендә баш бухгалтер һәм бухгалтерларның (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына каралган вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» нигезләмәнең 3 нче пунктында «Бухгалтерларның вазыйфаи хезмәт хакы түбәндәге күләмдә билгеләнә» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазифа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең |
|---|---|

| | |
|---|---|
| | башкарма комитетлары |
| | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер (1 ст.) | 29 700 |
| Бухгалтер (1 ст.) | 27 000 |

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http//vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2025 нче елның 1 нче маеннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Ф.Салахутдинов